| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.04.2024 Казан ш. № 206-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 30.09.2022 № 585-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 585-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында

Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре
министрлыгының
11.04.2024 № 206-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 585-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләр:

Түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7 пунктлар белән тулыландырырга:

2.3.6. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карарлары Министрлык боерыклары формасында кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетүдән баш тарту турында хат рәвешендә формалаштырыла.

2.3.7. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карары, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карарын электрон имза белән имзалаганда)”.

2.6.2 пунктның 4 подпунктында:

унберенче абзацны “тапшыра торган якның” дигән сүзләрдән соң «һәм гамәлгә куючының» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

ундүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

унбишенче абзацны көчен югалткан дип танырга.